| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ<br>ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27 июнь 2016ел № 3252

Төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә торган объектларны урнаштыру өчен, җир участоклары бирмичә һәм сервитутлар билгеләмичә, дәүләт яки муниципаль милектәге җирләрдән яки җир участокларыннан файдалануга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

Россия Федерациясе Җир кодексының 39.36 статьясы, 3 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт яки муниципаль милектәге җирләрдә яки җир участокларында җир участоклары бирмичә һәм сервитутлар билгеләмичә урнаштыру мөмкин булган объектлар исемлеген раслау турында» 2014 елның 3 декабрендәге 1300 номерлы РФ Хөкүмәте Карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә торган объектларны дәүләт яки муниципаль милектә булган җирләрдә яки җир участокларында, җир участоклары бирмичә һәм сервитутлар билгеләмичә урнаштыру тәртибен һәм шартларын раслау турында» 2015 елның 5 июнендәге 416 номерлы Карары, Башкарма комитетның «Муниципаль һәм дәүләт хезмәтләре исемлекләрен раслау турында» 2016 елның 5 июнендәге 2363 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә торган объектларны урнаштыру өчен, сервитутлар билгеләү һәм дәүләт яки муниципаль милектәге җирләрдән яки җир участокларыннан файдалануга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын (алга таба – административ регламент) кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе башлыгы И.З. Исхаковка административ регламентны тиешле мәгълүмат системаларында урнаштыру һәм «Интернет» челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтында

урнаштыру өчен «Мәгълүмати технологияләр үзәге» муниципаль автономияле учреждениесенә тапшыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе башлыгы И.З. Исхаковка йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы В.А. Гаврилов

Башкарма комитетның
2016 елның 27 июнендәге
3252 номерлы карарына
кушымта

## Төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә торган объектларны урнаштыру өчен, җир участоклары бирмичә һәм сервитутлар билгеләмичә, дәүләт яки муниципаль милектәге җирләрдән яки җир участокларыннан файдалануга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты

### 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә торган объектларны урнаштыру өчен, җир участоклары бирмичә һәм сервитутлар билгеләмичә, дәүләт яки муниципаль милектәге җирләрдән яки җир участокларыннан файдалануга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (алга таба – Регламент) Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль хезмәт күрсәтүнең стандартын һәм тәртибен билгели (алга таба – муниципаль хезмәт).

1.2. Муниципаль хезмәттән файдаланучылар: физик һәм юридик затлар (алга таба – гариза бирүче).

Әлеге Регламент «Реклама турында» 2006 елның 13 мартындагы 38-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә урнаштырылган тышкы реклама чаралары булган төзекләндерү объектларын урнаштыруга кагылмый.

1.3. Муниципаль хезмәт Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты (алга таба – Башкарма комитет) тарафыннан күрсәтелә.

Муниципаль хезмәтне башкаручы – Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе (алга таба – АШТһТҮИ).

1.3.1. Башкарма комитетның урнашу урыны: Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Хәсән Туфан проспекты, 23 йорт.

Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсенең урнашу урыны: Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Хәсән Туфан проспекты, 23 йорт, 249 кабинет.

Башкарма комитетның эш графигы:

дүшәмбе-җомга: 8:00 дән 17:00 сәгатькә кадәр, төшке аш вакыты: 12.00 дән 13.00 сәгатькә кадәр. Шимбә, якшәмбе: ял көннәре.

АШТһТҮИнең белешмә телефоны: 30-55-08.

Башкарма комитет бинасына керү – шәхесне раслаучы документлар буенча.

1.3.2. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайты адресы (алга таба – «Интернет» челтәре): (http:// www.nabchelny.ru.

1.3.3. Муниципаль хезмәт турында мәгълүмат алынырга мөмкин:

1) Башкарма комитет бүлмәләрендә урнашкан муниципаль хезмәт турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган мәгълүмат стендлары аша, мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү өчен;

2) «Интернет» челтәре аша муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында (http:// www.nabchelny.ru;

3) Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatar.ru/;

4) Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында (http:// www.gosuslugi.ru/;

5) Башкарма комитетта (АШТҺТҮИ):

телдән мөрәҗәгать иткәндә – шәхсән яки телефон аша;

язмача (шул исәптән электрон документ формасында) мөрәҗәгать иткәндә – кәгазьдә почта аша, электрон почта аша (gradostroitel@mail.ru).

1.3.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүмат, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында һәм гариза бирүчеләр белән эшләү өчен Башкарма комитет бүлмәләрендә мәгълүмати стендларда дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча АШТҺТҮИ белгече тарафыннан урнаштырыла.

1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

1) Россия Федерациясе Җир кодексы (РФ законнар җыентыгы, 29.10.2001, №44, ст. 4147) (алга таба – РФ Җир кодексы);

2) Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы (РФ законнар җыентыгы, 03.01.2005, №1 (1 өлеш), ст. 16 (алга таба – РФ Шәһәр төзелеше кодексы);

3) «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 06.10.2003, №40, ст. 3822) (алга таба – 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы-ФЗ Федераль законы);

4) «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 02.08.2010, №31, ст. 4179) (алга таба - 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон);

5) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт яки муниципаль милектәге җирләрдә яки җир участокларында җир участоклары бирмичә һәм сервитутлар билгеләмичә урнаштыру мөмкин булган объектлар исемлеген раслау турында» 2014 елның 3 декабрендәге 1300 номерлы Карары (Россия

Федерациясе законнар җыентыгы, 15.12.2014, №50, ст. 7089) (алга таба – РФ Хөкүмәте Карары);

6) «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (Татарстан Республикасы, №155-156, 03.08.2004) (алга таба – 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы);

7) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә торган объектларны дәүләт яки муниципаль милектә булган җирләрдә яки җир участокларында, җир участоклары бирмичә һәм сервитутлар билгеләмичә урнаштыру тәртибен һәм шартларын раслау турында» 2015 елның 5 июнендәге 416 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Карары (алга таба – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Карары);

8) «Яр Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлегенең Вәкиллекле органы тарафыннан 2005 елның 8 декабрендәге 6/5 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы (алга таба – шәһәр Уставы);

9) Башкарма комитетның 2016 елның 13 маендагы 2363 номерлы карары белән расланган «Муниципаль һәм дәүләт хезмәтләре исемлеген раслау турында» (алга таба – Башкарма комитетның 2013 елның 9 апрелендәге 2393 номерлы карары);

10) Башкарма комитет Җитәкчесенең 2012 елның 24 маендагы 372 номерлы боерыгы белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе турында нигезләмә (алга таба – идарә турында Нигезләмә);

11) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2014 елның 11 мартындагы147-р боерыгы белән расланган Эш регламенты (алга таба – Эш регламенты);

12) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Җитәкчесенең 2007 елның 16 июлендәге 754 номерлы боерыгы белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре (алга таба – Эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре).

1.5. Объектларны урнаштыру, әлеге Регламент нигезендә, гражданнарга яисә юридик затларга нинди дә булса хокук бирелмәгән җир участокларына карата, объектларны урнаштыру Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының 2014 елның 1 сентябрендәге 540 номерлы «Җир участокларын рөхсәт ителгән файдалану төрләре классификаторын раслау турында» боерыгы белән расланган җир участокларын рөхсәт ителгән файдалану төрләре классификаторы нигезендә билгеләнгән файдалану мөмкин булмаган очракта, аларны урнаштыру рөхсәт ителгән җир участокларына карата гамәлгә ашырыла.

Объектларны урнаштыру түләүле башкарыла. Искәрмәне түбәндәге төр объектлар тәшкил итә:

территорияне төзекләндерү элементлары;

геодезия, межалау, кисәтү һәм башка билгеләр, шул исәптән мәгълүмати табло (стела) һәм флагштоклар;

төзелеш өчен рөхсәт таләп ителми торган саклау корылмалары;

юллар, шул исәптән трасса буйлары һәм керү юллары, аларны урнаштыру өчен төзелешкә рөхсәт кирәкми;

янгын сулыклары һәм янгын сүндерү чараларының туплану урыннары;

пар чыгару буалары;

35 кВ. га кадәр көчәнеш класслы электр тапшыру линияләре, шулай ук алар белән бәйле трансформатор подстанцияләре, бүлү пунктлары һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән, аларны урнаштыру өчен төзелешкә рөхсәт кирәкми торган башка җиһазлар.

Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

техник хата – муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан кертелгән һәм документка кертелгән мәгълүматларның (муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе) документлардагы мәгълүматларга тәңгәл килмәвенә китергән хата (тасвирлама, басма, грамматик яки арифметик хата яисә шуңа охшаш хата).

## 2. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты

| Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына таләпнең исеме | Стандартка таләпләрнең эчтәлеге | Муниципаль хезмәт билгели торган норматив акт яки таләп |
|---|---|---|
| 2.1. Муниципаль хезмәтнең исеме | Төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә торган объектларны дәүләт яки муниципаль милектәге җирләрдә яки җир участокларында җир участоклары бирмичә һәм сервитутлар билгеләмичә урнаштыру. | РФ Хөкүмәте Карары |
| 2.2. Турыдан-туры муниципаль хезмәт күрсәтүче органның исеме | Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитеты исеменнән Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе | 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон<br>Шәһәр Уставы;<br>Идарә турында Нигезләмә |
| 2.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау | 1. Башкарма комитетның төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә торган объектларны урнаштыру өчен, сервитутлар билгеләү һәм дәүләт яки муниципаль милектәге җирләрдән яки җир участокларыннан файдалануга рөхсәт бирү турында карары (алга таба – карар).<br>2. Башкарма комитетның төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә торган объектларны урнаштыру өчен, сервитутлар билгеләү һәм дәүләт яки муниципаль милектәге җирләрдән яки җир участокларыннан файдалануга рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар. | ТР Министрлар Кабинеты Карары |
| 2.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы | Гариза биргән көннән башлап 10 эш көне эчендә. | ТР Министрлар Кабинеты Карарының 12 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| 2.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булып торган хезмәтләрне күрсәтү өчен, закон яки башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле, гариза бирүче тапшырырга тиешле документларның тулы исемлеге | 1) гариза (1 нче кушымта);<br>2) җир участогында объектлар урнашуның күршедәге җир участокларының урнашкан урыннарын билгеләргә мөмкинлек бирә торган схемасы (1:500 масштабындагы ситуацион план, адресы);<br>3) гариза бирүченең фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булганда), яшәү урыны һәм шәхесен таныклаучы документ реквизитлары - гариза физик зат тарафыннан бирелгән очракта<br>4) гариза бирүче вәкиленең фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булганда) һәм аның вәкаләтләрен раслаучы документ реквизитлары (чагыштыру өчен төп нөсхәләр һәм күчермәләре яки нотариаль расланган күчермәләр) - гариза гариза бирүченең вәкиле тарафыннан бирелгән очракта;<br>5) юридик затларның бердәм дәүләт реестрында гариза бирүченең исеме, урнашу урыны, оештыру-хокукый формасы һәм юридик затның Бердәм дәүләт теркәвенә алынуы турында мәгълүмат - гариза юридик зат тарафыннан бирелгән очракта;<br>6) гариза бирүченең Бердәм дәүләт реестрында урнашу урыны һәм дәүләт теркәве турында мәгълүматлар - гариза шәхси эшмәкәр тарафыннан бирелгән очракта;<br>7) объектларны урнаштыру проектын техник-икътисадый нигезләү яки кирәкле исәп-хисаплар. | ТР Министрлар Кабинеты Карары |
| 2.6. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар | Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында алына:<br>1) җир участогы турында кадастр өземтәсе (дәүләт күчемсез милек кадастрыннан өземтә);<br>2) җир участогының кадастр паспорты (дәүләт күчемсез милек кадастрыннан өземтә);<br>3) Бердәм дәүләт күчемсез милеккә хокуклар һәм аның белән | ТР Министрлар Кабинеты Карары |

| | | |
|---|---|---|
| карамагындагы һәм гариза бирүче тапшырырга хокуклы документларның тулы исемлеге | сату-алу килешүләре реестрыннан өземтә). | |
| 2.7. Норматив хокукый актларда каралган очракларда, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен килештерү таләп ителә һәм муниципаль хезмәт күрсәтүче башкарма хакимият органы тарафыннан гамәлгә ашырыла торган дәүләт органнарының, җирле үзидарә органнарының һәм аларның структур бүлекчәләренең исемлеге | 1) Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе;<br>2) Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе;<br>3) Башкарма комитетның хокук идарәсе;<br>4) Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсе. | Эш регламенты |
| 2.8. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | 1) документлар тиешле булмаган зат тарафыннан тапшырылу;<br>2) тапшырылган документлар әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегенә туры килмәү;<br>3) гаризада һәм гаризага теркәлгән документларда аларның эчтәлеген бертөрле аңларга мөмкинлек бирми торган килешенмәгән төзәтүләр, җитди бозулар булу;<br>4) документларның тиешле органга бирелмәве. | |
| 2.9. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату яки баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату өчен нигезләр каралмаган.<br>Баш тарту өчен нигезләр:<br>а) әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмау; | ТР Министрлар Кабинеты Карарының 14 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| | б) гаризада Россия Федерациясе Җир кодексының 39.36 статьясының 3 пункты нигезендә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган объектларның төрләре исемлегенә керми торган объектларның күз алдында тотылган төрләре күрсәтелгән;<br>в) объектларны урнаштыру өчен планлаштырылган җир участогы муниципаль милектә булмаган, дәүләт милке чикләнмәгән җир участокларына керми;<br>г) планлаштырыла торган җир участогы гражданнарга яисә юридик затларга бирелгән;<br>д) объектларны планлаштырыла торган җир участогында урнаштыру аны Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Җир участокларыннан рөхсәт ителгән файдалану төрләре классификаторын раслау турында» 2014 елның 1 сентябрендәге 540 номерлы боерыгы белән расланган рөхсәт ителгән җир участокларыннан файдалану төрләре классификаторы нигезендә рөхсәт ителгән файдалану төре нигезендә файдалану мөмкин булмавына китерә. | |
| 2.10. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында запрос биргәндә һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь срогы | Чират булганда, муниципаль хезмәттән файдалануга гариза бирү – 15 минуттан артык түгел.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь срогы 15 минуттан артырга тиеш түгел. | |
| 2.11. Гариза бирүченең муниципаль хезмәт күрсәтү турында запросын теркәү срогы, шул исәптән электрон рәвештә | Гариза кергән вакыттан башлап бер көн эчендә. | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.12. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга таләпләр | Бина гариза язу өчен өстәл һәм урындыклар, гариза тутыру үрнәкләре һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган | |
| 2.13. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга, гариза бирүчеләрне кабул итү, аларның көтеп тору урыннарына, шул исәптән Россия Федерациясенең инвалидларны социаль яклау турындагы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен уңайлылыгын тәэмин итүгә, андый хезмәтләр күрсәтү тәртибе турындагы визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматын урнаштыруга таләпләр | Муниципаль хезмәт күрсәтү янгын сүндерү системасы, документлар рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһазлар, мәгълүмати стендлар белән җиһазландырылган биналарда һәм бүлмәләрдә гамәлгә ашырыла.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү урынына инвалидлар өчен тоткарлыксыз керү тәэмин ителә (биналарга керү-чыгу һәм алар эчендә хәрәкәтләнү уңайлы булырга тиеш).<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедия мәгълүматы гариза бирүчеләргә уңайлы урыннарга урнаштырыла, шул исәптән инвалидларның мөмкинлекләре чикле булуын исәпкә алып | |
| 2.16. Муниципаль хезмәтне электрон рәвештә күрсәтү үзенчәлекләре | Муниципаль хезмәттән электрон рәвештә файдалану тәртибе турында консультацияне Интернет-кабул итү аша яки Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша алырга мөмкин.<br>Әгәр законда муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы гаризаны электрон рәвештә бирү каралган булса, ул очракта гариза Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр | |

| | | |
|---|---|---|
| | порталы (http://uslugi.tatar.ru) яки Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы (http:// www.gosuslugi.ru) аша бирелә. | |

## 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм үтәү сроклары, аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон рәвештә үтәү үзенчәлекләре

3.1. Муниципаль хезмәт күрсәткәндә гамәлләрнең эзлеклелеген тасвирлау

3.1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) гариза бирүчегә консультация бирү;

2) гаризаны кабул итү һәм теркәү;

3) ведомствоара запросларны формалаштыру һәм аларны муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү;

4) муниципаль хезмәт нәтиҗәсен әзерләү;

5) гариза бирүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен бирү.

3.1.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелегенең блок-схемасы әлеге Регламентка 3 нче кушымтада күрсәтелгән.

3.2. Гариза бирүчегә консультацияләр бирү

3.2.1. Гариза бирүче муниципаль хезмәттән файдалану тәртибе турында консультацияләр алу өчен шәхсән, телефон һәм (яки) электрон почта аша Башкарма комитетка мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

АШТһТҮИ белгече гариза бирүчегә консультация бирә, шул исәптән муниципаль хезмәттән файдалану өчен тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм башка мәсьәләләр буенча һәм кирәк булганда, гариза бланкын тутыруда ярдәм күрсәтә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм муниципаль хезмәттән файдалануның башка мәсьәләләре буенча консультацияләр.

3.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү

3.3.1. Гариза бирүче шәхсән яисә вәкаләтле зат аша Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә муниципаль хезмәт күрсәтү турында язмача гариза бирә һәм әлеге Регламентның 2.5 пункты нигезендә документлар тапшыра.

Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза электрон формада Башкарма комитетка электрон почта яки Интернет-кабул итү бүлмәсе аша җибәрелә. Электрон формада кергән гаризаны теркәү билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

3.3.2. Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече гамәлгә ашыра:

- гариза бирүченең шәхесен ачыклауны;

- гариза бирүченең вәкаләтләрен тикшерүне (ышаныч язуы буенча эш иткәндә);

- әлеге Регламентның 2.5 пунктында каралган документларның

булуын тикшерүне;

- тапшырылган документларның билгеләнгән таләпләргә туры килүен (документларның күчермәләре тиешенчә рәсмиләштерелүне, документларда бозып төзәтүләр, өстәп язулар, сызган сүзләр булмауны) тикшерүне.

Кимчелекләр булмаган очракта, эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече гамәлгә ашыра:

-гаризаны һәм теркәлгән документларны «Электрон документлар әйләнеше» системасы аша кабул итүне (алга таба – ЭДО);

гаризаны карап тикшерү өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрүне.

Әлеге Регламентның 2.8 пункты нигезендә документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, эш кәгазьләрен алып бару идарәсенең гаризалар кабул итүче белгече гариза бирүчегә гаризаны теркәү өчен каршылыклар булу турында хәбәр итә һәм кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең эчтәлеген язмача аңлатып, гариза бирүчегә гаризаны һәм документларны кире кайтара.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар түбәндәгечә гамәлгә ашырыла:

гаризаны һәм документларны кабул итү – 15 минут эчендә;

гаризаны теркәү – гариза кергән вакыттан башлап бер эш көне эчендә.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән һәм карап тикшерү өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрелгән гариза яисә кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең эчтәлеген язмача аңлатып, гариза бирүчегә кире кайтарылган гариза һәм аларга теркәлгән документлар.

3.3.3. Башкарма комитет Җитәкчесе гаризаны һәм документларны карап тикшерә һәм аларны АШТһТҮИ башлыгына җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гариза теркәлгән вакыттан башлап бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: АШТһТҮИ башлыгына җибәрелгән гариза һәм аңа теркәлгән документлар.

3.3.4. АШТһТҮИ башлыгы гаризаны һәм аңа теркәлгән документларны карап тикшерә һәм аларны АШТһТҮИ белгеченә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гариза теркәлгән вакыттан башлап бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: АШТһТҮИ белгеченә җибәрелгән гариза һәм аңа теркәлгән документлар.

3.4. Муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара запрослар формалаштыру һәм җибәрү

3.4.1. әлеге Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документларны тапшыру турында запросларны АШТһТҮИ белгече ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша электрон рәвештә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза кергән вакыттан башлап бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: хакимият органнарына җибәрелгән запрослар.

3.4.2. Мәгълүмат белән тәэмин итүчеләрнең белгечләре, ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша кергән запрослар нигезендә, сорала торган документларны (мәгълүматларны) бирәләр яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документның һәм (яки) мәгълүматның булмавы турында белдерү кәгазе җибәрәләр (алга таба – баш тарту турында белдерү кәгазе).

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар, федераль законнарда, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең хокукый актларында һәм федераль законнар нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында ведомствоара запроска җавап әзерләү һәм җибәрүнең башка сроклары билгеләнмәгән очракта, документлар (мәгълүматлар) бирә торган органга яки оешмага ведомствоара запрос кергән көннән башлап биш көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: АШТһТҮИ белгеченә җибәрелгән документлар (мәгълүмат) яисә баш тарту турында белдерү кәгазе.

3.5. Муниципаль хезмәт нәтиҗәләрен әзерләү

3.5.1. АШТһТҮИ белгече гамәлгә ашыра:

- гаризага теркәлә торган документлардагы мәгълүматларны тикшерү;

- әлеге Регламентның 2.9 пунктында каралган муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең булуын тикшерү.

Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, АШТһТҮИ белгече дәүләт яки муниципаль милектә булган җирләрдән яки җир участокларыннан файдалануга рөхсәт бирүдән баш тарту һәм төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә торган объектларны урнаштыру өчен җир участоклары бирүдән һәм сервитутлар билгеләүдән баш тарту турында карар проектын әзерли (алга таба – баш тарту турында карар) һәм аны имзалау өчен АШТһТҮИ башлыгына җибәрә.

Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта, АШТһТҮИ белгече гамәлгә ашыра:

- Башкарма комитетның дәүләт яки муниципаль милектә булган җирләрдән яки җир участокларыннан файдалануга рөхсәт бирү һәм төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә торган объектларны урнаштыру өчен җир участоклары бирүдән сервитутлар билгеләү турында карар проектын әзерләү (алга таба – карар проекты);

- карар проектын архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсенең архитектура, дизайн һәм реклама бүлеге башлыгына (алга таба – АШТһТҮИ бүлеге башлыгы) килештерүгә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гариза кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: карар проекты яки баш тарту турындагы АШТһТҮИ бүлеге башлыгына килештерүгә җибәрелгән карар.

3.5.2. АШТҺТҮИ бүлеге башлыгы карар проектын карап тикшерә, килештерә Башкарма комитетның Хокук идарәсенә (алга таба – Хокук идарәсе) яки АШТҺТҮИ башлыгына имза куюдан баш тарту турындагы карарны җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар, әлеге процедура тәмамланганнан соң, бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Хокук идарәсенә килештерүгә яисә АШТҺТҮИ башлыгына имза кую өчен җибәрелгән карар проекты.

3.5.3. Хокук идарәсе карар проектын карап тикшерә һәм килештерә һәм аны Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесенә килештерүгә җибәрә.

Тапшырылган документларның норматив хокукый актларга туры килмәве очрагында, Хокук идарәсе карар проектына карата күрсәтмәләр әзерли һәм аларны төзәтү өчен АШТҺТҮИ белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесенә килештерүгә җибәрелгән карар проекты яисә АШТҺТҮИ белгеченә җибәрелгән карар проектына карата кимчелекләр.

3.5.4. Хокук идарәсе карар проектындагы кимчелекләргә кисәтүләр җибәргән очракта, АШТҺТҮИ белгече кимчелекләрне төзәтә һәм карар проектын алга таба килештерү өчен Хокук идарәсенә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура кисәтүләр кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Хокук идарәсенә килештерүгә җибәрелгән төзәтелгән карар проекты.

3.5.5. Хокук идарәсе карарның төзәтелгән проектын карап тикшерә, аны килештерә һәм килештерүгә Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесенә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура карар проектына карата кимчелекләр төзәтелгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Хокук идарәсе тарафыннан килештерелгән һәм Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесенә килештерүгә җибәрелгән карар проекты.

3.5.6. Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе карар проектын карап тикшерә, килештерә һәм аны эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрә.

Процедураның нәтиҗәсе: эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгеченә җибәрелгән карар проекты.

3.5.7. Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече:

1) карар проектын ахыргы вариантта тикшерә;

2) вазыйфаи затларның кирәкле визалары, Башкарма комитет карарларын (боерыкларын) бирүгә реестрның булуын (булмавын) тикшерә;

3) карар проектын Башкарма комитет бланкында бастыра;

4) карар проектын имзалау өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура карар проекты эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Башкарма комитет Җитәкчесенә имзалау өчен җибәрелгән карар проекты.

3.5.8. Башкарма комитет Җитәкчесе карарны имзалый һәм аны теркәү өчен эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрә.

3.5.9 АШТһТҮИ башлыгы баш тарту турындагы карарны имзалый, теркәү һәм гариза бирүчегә бирү өчен АШТһТҮИ белгеченә җибәрә.

3.5.8 һәм 3.5.9 пунктлары белән билгеләнә торган процедуралар узган процедура тәмамланганнан соң бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

3.5.10. Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече:

1) карарны Башкарма комитет карарларын теркәү журналында терки;

2) карарларның күчермәләрен карарлар бирү реестры нигезендә бирә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура карарның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: теркәлгән, карарлар бирү реестры нигезендә бирелгән карар, карарның күчермәләре.

3.6. Гариза бирүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен бирү

АШТһТҮИ белгече мөрәҗәгать итүчегә Башкарма комитетның төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә торган объектларны урнаштыру өчен, җир участоклары бирмичә һәм сервитутлар билгеләмичә, дәүләт яки муниципаль милектәге җирләрдән яки җир участокларыннан файдалануга рөхсәт бирү турындагы карарын яки төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә торган объектларны урнаштыру өчен, җир участоклары бирмичә һәм сервитутлар билгеләмичә, дәүләт яки муниципаль милектәге җирләрдән яки җир участокларыннан файдалануга рөхсәт бирүдән баш тарту турында карарны бирә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гамәлгә ашырыла:

-гариза бирүче шәхсән килгән очракта - 15 минут эчендә;

Процедураның нәтиҗәсе: Башкарма комитетның мөрәҗәгать итүчегә бирелгән төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә торган объектларны урнаштыру өчен, җир участоклары бирмичә һәм сервитутлар билгеләмичә, дәүләт яки муниципаль милектәге җирләрдән яки җир участокларыннан файдалануга рөхсәт бирү турындагы карары яки нигезләнгән баш тарту.

3.7. КФҮ аша муниципаль хезмәт күрсәтү

3.7.1. Гариза бирүче муниципаль хезмәттән файдалану өчен КФҮгә мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

3.7.2. КФҮ аша муниципаль хезмәт күрсәтү КФҮнең Эш регламенты нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.7.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен КФҮдән документлар кергәндә, процедуралар әлеге Регламентның 3.3-3.5 пунктлары нигезендә гамәлгә ашырыла. Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе КФҮгә җибәрелә.

3.8. Техник хаталарны төзәтү.

3.8.1. Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булган документта техник хата ачыкланган очракта, гариза бирүче эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә тапшыра:

техник хатаны төзәтү турында гариза (2 нче кушымта);

гариза бирүчегә техник хата булган муниципаль хезмәт нәтиҗәсе буларак бирелгән документ;

юридик көчкә ия булган, техник хатаның булуын таныклаучы документлар.

Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булган документта күрсәтелгән мәгълүматларда техник хатаны төзәтү турында гаризаны гариза бирүче (аның вәкиле) шәхсән үзе, яисә почта аша (шул исәптән электрон почта аша), яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы яки КФҮ аша бирә.

3.8.2. Документларны кабул итү өчен җаваплы белгеч техник хатаны төзәтү турында гариза кабул итә, теркәлгән документлар белән гаризаны терки һәм аларны АШТһТҮИга тапшыра.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гаризаны теркәгәннән соң бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән, АШТһТҮИ белгеченә карап тикшерүгә җибәрелгән гариза.

3.8.3. АШТһТҮИ белгече документларны карап тикшерә һәм хезмәт нәтиҗәсе булган документка төзәтмәләр кертү максатларында, әлеге Регламентның 3.5 пунктында каралган процедураларны гамәлгә ашыра, төзәтелгән документны гариза бирүчедән (аның вәкиленнән) техник хата булган документның төп нөсхәсен алу белән шәхсән үз имзасы белән бирә яки гариза бирүче адресына почта аша (электрон почта аша) документ алу мөмкинлеге турында хат җибәрә.

Әлеге пунктча белән билгеләнә торган процедура техник хата ачыкланганнан яки теләсә кайсы кызыксынган заттан җибәрелгән хата турында гариза алынганнан соң өч көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә бирелгән (җибәрелгән) документ.

4. Муниципаль хезмәт күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формалары

4.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту гариза бирүчеләрнең хокукларын бозу очракларын ачыклау һәм бетерү, муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлешен тикшерү, Башкарма комитетның вазыйфаи затларының карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карарлар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешен контрольдә тоту формалары булып тора:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү буенча документлар проектларын тикшерү һәм килештерү. Тикшерү нәтиҗәсе булып проектларны визалау тора;

2) билгеләнгән тәртиптә үткәрелә торган эш кәгазьләрен алып баруны тикшерүләр;

3) билгеләнгән тәртиптә муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлешенә контроль тикшерүләр үткәрү.

Контроль тикшерүләр планлы булырга мөмкин (Башкарма комитетның ярты еллык яки еллык эш планнары нигезендә башкарыла) һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерүләр уздырганда муниципаль хезмәт күрсәтү (комплекслы тикшерүләр) белән бәйле барлык мәсьәләләр каралырга мөмкин яки гариза бирүченең конкрет мөрәҗәгате буенча карала ала.

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә һәм карарлар кабул иткәндә гамәлләр кылуны тикшереп тору максатларында Башкарма комитет Җитәкчесенә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмәләр тапшырыла.

4.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ процедуралар тарафыннан билгеләнгән гамәлләр эзлеклелеге буенча агымдагы контроль Башкарма комитет Җитәкчесенең муниципаль хезмәт күрсәтү буенча эшне оештыру өчен җаваплы урынбасары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.3. Агымдагы контрольне гамәлгә ашыра торган Башкарма комитетның вазыйфаи затлары исемлеге Башкарма комитетның структур бүлекчәләре турындагы нигезләмәләр һәм вазыйфаи инструкцияләр белән билгеләнә.

Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча, гариза бирүчеләрнең хокукларын бозу очраклары ачыкланган очракта, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Башкарма комитет Җитәкчесе гариза бирүчеләрнең мөрәҗәгатьләрен вакытында карап тикшерү өчен җаваплы.

Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, АШҺТҮИ башлыгы әлеге Регламентның 3 бүлегендә күрсәтелгән административ гамәлләрне вакытында һәм (яки) тиешенчә үтәмәгән өчен җаваплы.

Муниципаль хезмәт күрсәтү барышында кабул ителә торган карарлар һәм гамәлләр (гамәл кылмау) өчен Башкарма комитетның вазыйфаи затлары һәм башка муниципаль хезмәткәрләре законда билгеләнгән тәртиптә җаваплы.

## 5. Башкарма комитетның, аның вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең, шулай ук КФҮнең, КФҮ хезмәткәрләренең карарларына һәм эш гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе

5.1. Муниципаль хезмәттән файдаланучылар Башкарма комитетның муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы хезмәткәрләренең карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр тәртиптә – Башкарма комитетка, КФҮ хезмәткәрләре буенча – КФҮгә яисә КФҮне оештыручы булып исәпләнгән гавами-хокукый берәмлекнең тиешле дәүләт хакимияте органына (җирле үзидарә органына) шикаять бирергә хокуклы.

Гариза бирүче шикаять белән мөрәҗәгать итәргә мөмкин, шул исәптән түбәндәге очракларда:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү турында запросны теркәү срогын бозу;

2) муниципаль хезмәт күрсәтү срогын бозу;

3) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең хокукый актларында тапшыру яки гамәлгә ашыру каралмаган документлар яки мәгълүмат яисә эшләрне гамәлгә ашыруны таләп итү;

4) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең хокукый актларында тапшыру каралган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) баш тарту өчен нигезләр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең хокукый актларында каралмаган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту;

6) муниципаль хезмәт күрсәткәндә гариза бирүчедән Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең хокукый актларында каралмаган түләү таләп итү;

7) Башкарма комитетның, Башкарма комитет вазыйфаи затының, КФҮнең, КФҮ хезмәткәренең муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән ялгышларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуы яисә андый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозу;

5.2. Шикаять язма рәвештә кәгазьдә яки электрон рәвештәБашкарма комитетка яки Башкарма комитет Җитәкчесенә бирелә.

Шикаять почта аша, КФҮ аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтыннан (http://www.nabchelny.ru), КФҮ, Татарстан Республикасының бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (http://uslugi.tatar.ru/), Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы (http://www.gosuslugi.ru/) рәсми сайтыннан файдаланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук гариза бирүчене шәхси кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин.

5.3. Шикаятьне карап тикшерү срогы – ул теркәлгән көннән башлап унбиш эш көне эчендә. Башкарма комитетның, КФҮнең гариза бирүчедән документларны кабул итүдән яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуыннан риза булмыйча шикаять бирелгән очракта яки шундый төзәтүләрнең билгеләнгән срогы бозылудан риза булмыйча шикаять бирелгән очракта – ул теркәлгән көннән башлап биш эш көне

эчендә.

5.4. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш.

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять бирелә торган Башкарма комитетның, Башкарма комитет вазыйфаи затының яки Башкарма комитет муниципаль хезмәткәренең исеме;

2) гариза бирүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда), яшәү урыны турында мәгълүмат яисә гариза бирүче – юридик затның исеме, урнашу урыны турында мәгълүмат, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булганда) һәм гариза бирүчегә җавап җибәрелергә тиешле почта адресы;

3) Башкарма комитетның, Башкарма комитет вазыйфаи затының яки Башкарма комитет муниципаль хезмәткәренең, КФҮнең, КФҮ хезмәткәренең шикаять бирелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүмат;

4) гариза бирүченең Башкарма комитетның, Башкарма комитет вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәткәренең, КФҮнең, КФҮ хезмәткәренең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән нинди нигездә килешмәвенең дәлилләре.

5.5. Шикаятькә шикаятьтә бәян ителгән хәлләрне раслаучы документларның күчермәләре теркәлергә мөмкин. Бу очракта шикаятьтә аңа теркәлгән документлар исемлеге язып куела.

5.6. Шикаять аны биргән муниципаль хезмәттән файдаланучы тарафыннан имзалана.

5.7. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Башкарма комитет Җитәкчесе (аны алмаштыручы зат) түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында, Яр Чаллы шәһәренең муниципаль хокукый актларында түләтү каралмаган акчаларны гариза бирүчегә кире кайтару рәвешендә, шулай ук башка формаларда;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта.

5.8. Әлеге Регламентның 5.7 пунктында күрсәтелгән карар кабул ителгән көннең икенче көненнән дә соңга калмый, гариза бирүчегә язма рәвештә һәм гариза бирүченең теләге буенча электрон рәвештә шикаятьләрне карап тикшерү нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап җибәрелә.

5.9. Шикаять тулысынча яки өлешчә канәгатьләндерелгән очракта, Башкарма комитет Җитәкчесе кимчелекләрне бетерү максатында кабул ителергә тиешле чараларны билгели. Шикаятьне карап тикшерү барышында яки аның нәтиҗәләре буенча административ хокук бозулар яки җинаять составы билгеләре ачыкланган очракта, Башкарма комитет Җитәкчесе

булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

5.10. Муниципаль хезмәт күрсәтүгә җаваплы вазыйфаи затның карары, гамәлләре (гамәл кылмавы) Россия Федерациясе законнары нигезендә суд тәртибендә шикаять ителергә мөмкин.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы Н.И. Галиева

Төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә торган объектларны урнаштыру өчен, җир участоклары бирмичә һәм сервитутлар билгеләмичә, дәүләт яки муниципаль милектәге җирләрдән яки җир участокларыннан файдалануга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
1 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге
Башкарма комитеты Җитәкчесе
Р.Ә. Абдуллинга
кемнән

______________________________________________
(физик затлар гариза биргән очракта – фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда), яшәү урыны, шәхесне таныклаучы документ реквизитлары)

______________________________________________
(юридик затлар гариза биргән очракта – гариза бирүченең исеме, урнашу урыны, оештыру-хокукый формасы һәм Бердәм дәүләт юридик затлар реестрында дәүләт теркәлүе турында мәгълүматлар)

______________________________________________
(шәхси эшмәкәрләр гариза биргән очракта – гариза бирүченең урнашу урыны һәм Бердәм дәүләт шәхси эшмәкәрләр реестрында дәүләт теркәлүе турында мәгълүматлар)

______________________________________________,
(гариза бирүче вәкиле гариза биргән очракта - гариза бирүче вәкиленең фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булганда) һәм аның вәкаләтләрен таныклаучы документ реквизитлары)

______________________________________________
(почта адресы, электрон почта адресы, гариза бирүче яки гариза бирүче вәкиле белән элемтә өчен телефон номеры)

Урнаштыруга рөхсәт бирүегезне сорыйм ______________________________

______________________________________________________________________________
(Россия Федерациясе Җир кодексының 39.36 статьясы, 3 пункты нигезендә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган исемлеккә туры китереп күздә тотылган объектның төре)

______________________________________________________________________________районында
(күздә тотылган объектларның урнашу урыны, аларның планлаштырылган җир участогында урнашуының нигезлелеге, шулай ук объектларны урнаштыру өчен кирәкле җир участогының якынча мәйданы зурлыгы)

______________________________________________________________________________
(урнаштырыла торган объектлар өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнә торган саклау, санитар-саклау, башка зоналар булдыру зарурлыгы (алга таба – махсус шартлары булган җирләрдән файдалану)

______________________________________________________________________________,

(жир участогының кадастр номеры – әгәр барлык жир участогыннан файдалану планлаштырылса, яки территория чикләренең характерлы нокталары координатлары – әгәр жирләрдән яки жир участогы өлешеннән файдалану планлаштырылса)

срогы ______________________________________________________________ .
(жирдән файдалануның күздә тотылган срогы)

Дата                                                                                    Имза ________________

Төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә торган объектларны урнаштыру өчен, җир участоклары бирмичә һәм сервитутлар билгеләмичә, дәүләт яки муниципаль милектәге җирләрдән яки җир участокларыннан файдалануга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы
Яр Чаллы шәһәре
муниципаль берәмлегенең
Башкарма комитет
Җитәкчесенә
_______________________________
Кемнән:
________________________

Техник хатаны төзәтү турында
гариза

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә җибәрелгән хата турында хәбәр итәм
___________________________________________________________________________
(хезмәтнең исеме)

Язылган: ___________________________________________________________
___________________________________________________________________________
Дөрес мәгълүматлар: _________________________________________________
___________________________________________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны төзәтүне һәм муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булып саналган документка тиешле үзгәрешләр кертүне сорыйм.

Түбәндәге документларны терким:

1.

2.

3.

Техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны кире кагу хакында карар кабул ителгән очракта, андый карарны түбәндәгечә җибәрүне сорыйм:

электрон документны E-mail: ______________________ адресына җибәрү юлы белән;

кәгазьдә расланган күчермә рәвешендә почта аша түбәндәге адреска җибәрүне:

_____________________________________________________________________________.

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә (җыюга, системалаштыруга, туплауга, саклауга, аныклауга (яңартуга, үзгәртүгә), файдалануга, таратуга (шул исәптән тапшыруга), блокировкалауга, персональ мәгълүматларны юкка чыгаруга, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү кысаларында шәхси белешмәләрне эшкәртү өчен кирәкле булган башка төрле гамәлләргә), шул исәптән автоматлаштырылган режимда, муниципаль хезмәт күрсәтү максатларында муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан алар нигезендә карарлар кабул итүне дә кертеп, үземнең ризалыгымны, шулай ук минем тарафтан күрсәтелгән затның ризалыгын раслыйм.

Моның белән раслыйм: әлеге гаризага теркәлгән, минем шәхескә һәм минем тарафтан күрсәтелгән затка кагыла торган, шулай ук түбәндә минем тарафтан кертелгән мәгълүматлар дөрес. Гаризага теркәлгән документлар (документларның күчермәләре) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләргә туры килә, гаризаны тапшыру вакытына бу документлар гамәлдә һәм төгәл мәгълүматларны үз эченә ала.

Миңа күрсәтелгән муниципаль хезмәтнең сыйфатын бәяләү буенча телефон аша сораштыруда катнашуга ризалыгымны бирәм: _________________.

______________ __________________ (
________________)
(дата) (имза)

Төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә торган объектларны урнаштыру өчен, җир участоклары бирмичә һәм сервитутлар билгеләмичә, дәүләт яки муниципаль милектәге җирләрдән яки җир участокларыннан файдалануга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
3 нче кушымта

## Муниципаль хезмәт күрсәтү гамәлләренең эзлеклелек блок-схемасы




АШТҺТҮИ белгече кергән документлар нигезендә карар проектын әзерли һәм аны килештерүгә АШТҺТҮИ башлыгына җибәрә
АШТҺТҮИ башлыгына килештерүгә җибәрелгән карар проекты
АШТҺТҮИ бүлеге башлыгы карар проектын килештерә һәм Хокук идарәсенә җибәрә
Килештерелгән, Хокук идарәсенә килештерүгә җибәрелгән карар проекты
Баш тарту турында АШТҺТҮИ башлыгына имзалауга җибәрелгән карар
АШТҺТҮИ башлыгы баш тарту турында карарны имзалый һәм теркәү һәм гариза бирүчегә бирү өчен АШТҺТҮИ белгечена җибәрә
Баш тарту турында имзаланган, теркәү һәм гариза бирүчегә бирү өчен АШТҺТҮИ белгеченә җибәрелгән карар
АШТҺТҮИ белгече баш тарту турында карарны терки һәм гариза бирүчегә җибәрә
Баш тарту турында имзаланган, гариза бирүчегә җибәрелгән карар
Хокук идарәсе карар проектын карап тикшерә, килештерә һәм Аппарат Җитәкчесенә җибәрә яисә кимчелекләр әзерли һәм АШТҺТҮИ белгеченә җибәрә
Килештерелгән, Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесенә җибәрелгән карар проекты
АШТҺТҮИ белгече Хокук идарәсенең карар проектына кимчелекләрен төзәтә һәм Хокук идарәсенә җибәрә


Аппарат Җитәкчесе карар проектын килештерә һәм эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрә
Килештерелгән, эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрелгән карар проекты
Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече карар проектын тикшерә һәм Башкарма комитет Җитәкчесе бланкында бастыра
Башкарма комитет Җитәкчесенә имзалауга җибәрелгән карар проекты
Башкарма комитет Җитәкчесе карар проектын имзалый һәм эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрә
Имзаланган һәм эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрелгән карар проекты
Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече карарны терки һәм күчермәсен тарату реестры нигезендә җибәрә
Тарату реестры нигезендә җибәрелгән карар
АШТҺТҮИ белгече карарны гариза бирүчегә бирә
Гариза бирүчегә бирелгән карар

Кушымта
(белешмә)

Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы һәм аның
үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның
реквизитлары

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе башлыгы | 30-55-08 | gradostroitel@mail.ru |